**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ИСКЕ КАРМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**№ 70** **24 сентябрь 2018 ел**

**Җирле референдум үткәрү инициативасы турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьяларына, Татарстан Республикасы Законының 18 статьясына ярашлы 24.04.2004 № 23-ТРЗ «Җирле референдум турында», Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Иске Кармәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кармәт авыл җирлеге Советы:

1.Җирле референдум үткәрү инициативасы:

2019 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кармәт авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге уку формасында белем алучы студентлардан тыш, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп, 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы:

I. торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге: - Иске Кармәт авылында Вахитов урамы, Тукай урамы, Татарстан урамы, Чапаев урамы, М.Җәлил урамы буенча юл полотносын ком һәм вак таш белән күмү - кышкы чорда Иске Кармәт 2 авылы автомобиль юлларын тоту. Торак пункт территориясен төзекләндерүне оештыру, аларны үтәүне контрольдә тоту, торак пункт территориясен күрсәтелгән Кагыйдәләргә ярашлы төзекләндерүне оештыру: - Иске Кармәт авылын, Коминтерн урамын, Чапаев урамын яктырту өчен энергия саклаучы лампалар сатып алу һәм урнаштыру. Торак пунктта яшәүчеләрнең күпләп ял итү өчен шартлар тудыру һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру, шул исәптән гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буйларына иркле керүен тәэмин итү :

Иске Кармәт авылындагы чишмәне ремонтлау өчен товарлар (төзелеш материаллары) сатып алу

"ӘЙЕ" «ЮК».

2. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://aksubaevo.tatar.ru Аксубай муниципаль районы Иске Кармәт авыл җирлегенең мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

ТР Аксубай муниципаль районы
Иске Кармәт авыл җирлеге
Советы Рәисе: Ф.З.Мусабиков

СОВЕТ СТАРОКИРЕМЕТСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ